**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Сарлинского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Центральная, д. 68А, село Сарлы,
Азнакаевского муниципального района, 423315
Тел. 36-5-34

Үзәк урам, 68А, Сарлы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423315
Тел. 36-5-34

**КАРАР**
«09» ноябрь, 2021 ел, №3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына бюджет турында " гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджет проекты турында фикер алышуда катнашу өчен ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10. 2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 21.04.2012 ел № 42 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык алдында тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2021 елның 29 ноябре 13.00 сәгатьтә;

- үткәрү урыны- Сарлы авылы КФҮ бинасы;

- тикшерелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Сарлы авылы, Үзәк урам, 68А.

4. Гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль Сарлы авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына бюджеты турында»гы карар проектын Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakayevo.tatarstan.ru. адресы буенча 2021 елның 10 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлеш контролен үз артымнан калдырам.

Башлык М.Р.Шәрипов

